гәүдәләнгән татар театрының тарихы. Хезмәттә төрле фондлардан: Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, Казан (Идел буе) федераль университетының Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсе, ТР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, ТР Милли музее, С. Сәйдәшев исемендәге музейдан 320 чыганак анализлана. Татар театры үсешенең төрле этапларында афиша эшләүнең эчтәлеге, стилистикасы, сәнгати үзенчәлекләре язманың тикшерү предметын билгели. Әлеге хезмәтнең яңалыгы шунда: ул китап мәдәнияте гаять бай традицияләргә ия булган татар халкының татар театры плакат сәнгате тарихыннан беренче тикшеренү булып тора. Мәкаләдә афиша һәм плакатларның, театрның катлаулы тарихи юлын, төп үсеш тенденцияләрен чагылдырып, аның үзенчәлекле билгесе булып китүе дәлилләнә.

**Төп төшенчәләр:** татар театры, татар драматургиясе, афиша, плакат, сәнгать белеме.

Тасвирый сәнгатьнең үзенчәлекле төрләренең берсе булган Казан плакаты турында күп кенә фәнни хезмәтләр бар [Корнилов, 1929], [Улемнова, 2014]; [Улемнова, 2005]; [Червонная, 1978]. Реклама белән сәнгатьнең мөстәкыйль әсәрләре чигендәге үзенчәлекле жанр буларак ул әлегә тиешенчә өйрәнелмәгән һәм тулысынча җыеп бетерелмәгән.

Сәнгать тарихчысы, сәяси плакатларны тикшерүче П. Корнилов Казанда плакат барлыкка килүне Февраль инкыйлабы һәм рәссам К. Чеботарев [Корнилов, б. 4] исеме белән бәйли һәм аның 1920 елларда Ф. Гаврилов җитәкләгән Дәүләт сәнгать остаханәләрендә югары үсешкә ирешүе турында болай ди: «Тасвирый сәнгатьнең бу төре бөтен дөньяга бөек социаль фактор һәм массаларга тәэсир итү чарасы буларак сәнгатьнең әһәмиятен бик ачык итеп күрсәтте» [Корнилов, б. 1].

Рус театр плакаты тарихын өйрәнүдә беренче адымнарны Ю. Благов белән Е. Ключевская ясый [Благов, 2002]. Алар 2002 елда «Казань» журналында басылган мәкаләләрендә ике гасыр дәвамындагы (1836 елдан алып бүгенге көнгә кадәр) театр афишаларына гомуми күзәтү ясыйлар. Аннан мәгълүм булганча, иң яхшы үрнәкләр Казан шәһәр театры һәм Казан Зур театрына карый. Хәзерге вакытта татар театр плакатын анализлауга багышланган махсус тикшеренүләр, Б. Гыйззәтнең газетада басылган мәкаләсеннән кала [Гиззат, 1956], юк дәрәҗәсендә. Бүгенге театр плакаты казанышлары беренче тапкыр 2003 елда «Современная сценография Татарстана» дигән республика күргәзмәсендә күрсәтелде, аның нәтиҗәләре шул ук исемдәге каталогта басылып та чыкты [Султанова, 2003].

XX гасыр башыннан алып хәзерге көнгә кадәр тупланган йөзләрчә данәдәге афишаларның уникаль үрнәкләре театр архивларында, ТР Милли музеенда, С. Сәйдәшев музеенда, Казан федераль университеты китапханәсендә, ТР ФАнең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (алга таба ТӘҺСИ) Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана.

Аларны Татар дәүләт академия, Татар художество эшчеләр («Эшче»), Колхоз-совхоз (күчмә) театрлары афишалары тәшкил итә. Афишалар Казандагы И. Харитонов типографиясендә, «Татполиграф»та 100, 200, 250 (гастроль спектакльләре өчен сирәк кенә 500) данәдә басылган. Бу плакатлар зур форматта (48х72, 97х75, 76х108 см) эшләнгән.

Спектакльләр Сәүдәгәрләр собраниесе, Зур театр, Шәрык клубы, «Рус Швейцариясе» биналарында һәм башка урыннарда куела. Татар театры формалашу чорында Казандагы сәхнә тормышының турыдан-туры шаһите булган кульязма афишалар аеруча кызыксыну уята. Күпләре үзешчән дәрәҗәдә генә бизәлгән булсалар да, ул чорның плакат сәнгате татар театры тарихының гаҗәеп кызыклы сәхифәләрен ача.

Шуңа да игътибар итәргә кирәк: плакат материалларын өйрәнгәндә, җитди генә кыенлыклар белән очрашырга туры килә: әйтик, даталары куелмау, үлчәмнәре, тиражлары, авторларының билгесезлеге, нәшриятлары күрсәтелмәү - болар барысы да плакатларда күтәрелгән темаларны тулырак ачыклау өчен таләп ителгән библиографияне төгәл эшләргә комачаулый.

Тупланган материалларны анализлау күрсәткәнчә, плакат авторлары үз эшләрен яхшы белгәннәр һәм, тамашачы зәвыгын истә тотып, реклама продукциясе булган афишаларга карата куелган төп таләпләрне үтәргә тырышканнар.

Беренчедән, һәр плакатка хас булганча, театр плакатына да күпсүзлелек рөхсәт ителми. Лаконизм, кыскалык - бу жанрда иҗат итүче рәссам өчен төп канун. Театр плакатын катлаулы ребуска әйләндерергә ярамый, шулай

да һәр сәнгать әсәрендәгечә, монда да, тамашачыны җәлеп итү өчен, ниндидер серлелек булу зарури.

Сәнгатьнең синтезга нигезләнгән төре буларак, тасвирый һәм сәхнә сәнгате плакатының әдәби образлылыгы түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш: композиция осталыгы, график һәм сынлы тәэсирлелек, полиграфик таләпләрне истә тоту. Шул ук вакытта афишадан спектакльнең идея һәм сәнгати үзенчәлеген, конкрет бер коллективта аның стилистик гәүдәләнешен, ягъни театр постановкасының эстетик рухын тамашачыга җиткерә алу да сорала.

XIX гасыр ахырында әле гаилә спектакльләре рәсми белдерүләрсез һәм билетлар сатылмыйча гына уздырылу сәбәпле, алар турында тар даирә кешеләре генә белә.

Татар театр афишасы формалашуның тәүге адымнары беренче театр труппалары «Сәйяр» (1907) һәм «Нур» (1912) эшчәнлеге белән бәйле.

Татар театрының беренче афишасы 1905 елда гомум инкыйлаби күтәрелеш чорында барлыкка килә. Б.Гыйззәт язганча, ул төсле бизәлештә һәм рус телендә була [Гиззат, 1956]. Анда Россиядә беренче тапкыр мөселман артистлары труппасының рәсми рәвештә рус һәм татар телләрендә спектакль күрсәтүе игълан ителә. Программада: А. Грибоедовның «Горе от ума» һәм Н. Гогольнең «Ревизор», шулай ук А. Островскийның «Свет и тьма» (ирекле тәрҗемәсе «В чужом пиру похмелье») комедияләреннән күренешләр.

Бу, чыннан да, зур форматтагы тамашачы зәвыгы, ихтыяҗы һәм үзенчәлеге исәпкә алып эшләнгән реклама афишасы була. Спектакльне оештыручылар татар хатын-кызы спектакльгә бармас, чөнки анда аңа бөркәнчексез, чит ирләр арасында утырырга туры киләчәк, дигән фараз белән газетада басылган белдерүләрдә дә, афишада да бельетажның фәкать хатын-кыз тамашачыга гына билгеләнүен, теләгән мөселман хатын-кызлар өчен анда нәфис вуаль битлек тә булуын махсус күрсәтәләр. Бельетажга керү, коридор һәм тышкы киемне саклау элгечләре ир-атлар үтеп кермәслек итеп көйләнә. Хезмәт күрсәтүчеләр руслар була [Кумысников, б. 35].

Оренбургта беренче профессиональ труппаны оештыручы И. Кудашев-Ашказарский, тамашачыларны күбрәк җәлеп итү өчен, афишалар бизәлешендә татар публикасы яратып карый торган цирк программалары афишасы рәвешендә кабарынкы (катлаулы) итеп эшләнгән формалардан файдалана. И. Кудашев-Ашказарскийның «Наданнар илә галимнәр», А Чехов хикәяләре буенча сәхнәләштерелгән «Хирургия» һәм «Гыйлем тәшрих, касыйд» спектакльләреннән соң кичә программасына, төп спектакльгә өстәмә буларак, декламация, җыр, бию кебек номерлардан тыш, фейерверк та кертелә.

Дин әһелләре театр эшчәнлегенә фанатикларча каршы чыксалар да, беренче татар труппасын оештыручылар, үзләре дә кайчандыр мәдрәсә шәкертләре булганлыктан, исламга хөрмәт белән карыйлар. Мөселман бәйрәмнәре уңае белән төрле урыннарда спектакльләр күрсәтәләр. Мәсәлән, 1913 елның 28 октябрендә Корбан бәйрәме хөрмәтенә Мөселман драма артистлары ширкәтенең«Нур» күчмә труппасы Оренбургның шәһәр театрында Кавказ мөселманнары көндәлек тормышын яктырткан «Мөсыйбәте Фәхретдин» трагедиясен (Н. Вәзир-Задә әсәре, Г. Нугайбәк тәрҗемәсе) күрсәтәләр. Анда труппадагы һәркем катнаша. Афишасы нәсх стилендә эшләнгән. ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘҺСИнең Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә сакланган тагын бер афишада И. Кудашев-Ашказарский труппасы тарафыннан «Луна-парк» бакчасы театрында зур кичә оештырылуы, «Әдәпсезләр» спектакле күрсәтелүе, шулай ук 1918 елның 30 июнендә Ураза бәйрәме хөрмәтенә «Мескен Фатих» спектакле куелачагы турында хәбәр ителә. 1920 еллар ахырына кадәр афишаларда цирк тамашалары элементлары кулланыла. Мәсәлән, 1918 елның гыйнварында Г. Монасыйповның «Ирем кайтты», «Имчеләр корбаны» спектакльләре өчен чәчәк орнаментлары чигелгән кульяулык рәвешендә бизәлгән афиша программасында «На вечере дивертисмент, танцы, лотерея, американский аукцион, серпантин и др.» дигән сүзләр дә язылган [Г. Камал театры архивы].

Гастроль афишаларын бизәүдә дә цирк элементлары кулланыла. Мәсәлән, Г. Камалның «Бәхетсез егет» спектакле постановкасына әзерләнгән афиша текстына диагональ буенча рус телендә һәм нәсх стилендеге (гарәп язуының бер төре) татар вариантында болай дип язылган: «Зал һәм киосклар көнчыгыш зәвыгынча бизәлә. Антракт вакытында оркестр милли көйләр башкарачак. Спектакльдән сон, биюләр, конфетти көрәшләре, серпантин,

бомбачыклар, очучы почта булачак» («Казан» милли-мәдәни үзәгенең даими экспозициясе).

Театр афишасының беренче рәссамы дип, бик хаклы рәвештә драматург Галиәсгар Камал исемен атый алабыз. Татар шрифтларының утызлап яңа төре (аларның егермедән артыгы 1909 еллардан И. Харитонов типографиясендә китаплар басуда кулланыла) барлыкка килүдә дә аның хезмәте зур [Каримуллин, б. 52]. Плакат сәнгатендә татар театр афишаларының мөстәкыйль график жанры буларак формалашуы да Г. Камал белән бәйле. Л. Аитов искә алганча, афишаларны, типографиядә бастырудан бигрәк, кулдан ясарга тырышалар. Гарәп каллиграфиясен яхшы белгән Г. Камал үзенең улы Әнәс белән һәр спектакльгә 40-50шәр афиша эшли [Аитов, б. 105-106]. Алар, хәрефләрдән генә төзелмичә, Г. Камал рәсемнәре төп урынны биләгән чын сәнгати композицияләрне тәшкил итәләр. Авторның үз бенефисы афишасы аеруча матур бизәлгән була. Профессиональ каллиграф буларак, Г. Камал афишаларда төрле типтагы һәм үлчәмдәге хәрефләрне төрле декоратив орнаментларга охшатып эшли. Әйтик, 1914 елның 22 декабрендә Яңа клубта куелган «Уйнаш», 1916 елның 15 августында күрсәтелгән «Кечкенә сугыш», «Җилкуарлар» спектакльләре постановкалары өчен әзерләнгән афишалар, нәсх стилендәге бизәкле каллиграфик иҗат үрнәге булып торалар (болар Татарстан Республикасы милли музеенда саклана). Шунысы да мөһим: баштагы дистә еллар театр афишалары аерылып тора. Аларда, спектакль атамасы, анда катнашучылар һәм башкаручылар исемлегеннән тыш, тамашадан соң уздырыла торган музыкаль кичәләр яки башка чараларның программалары да күрсәтелә. Мәсәлән, 1908 елның 24 ноябрь датасы куелган афишада түбәндәгеләр язылган: «Поиск жениха, или Беда позорного объявления». Затем литературный вечер и танцы. Прочее: С. Рамиев и Г. Тукаев будут читать свои последние стихи. Оркестр татарской молодежи будет играть национальные мелодии. В спектакле участвуют: Гиззатуллина, Булгарская» (нәсх почеркы; ТӘҺСИ Язма һәм музыкаль мирас үзәге архивы).

Тамашачыларны күбрәк җәлеп итү максаты белән, кайчакта спектакль исеменә аңлатма бирелә. Мәсәлән: «1914 елның 22 декабрендә Яңа клубта А. Кариев җитәкчелегендәге Мөселман драма артистлары ширкәте «Уйнаш» спектаклен күрсәтә». Шунда ук аста кириллица хәрефләре белән болай дип тә өстәлгән: «Каенана өйдә булса, өйнең асты өскә килә». «Керү рекомендация буенча түгел. Антракт вакытында Фишкин җитәкчелегендә оркестр уйный».

Беренче Бөтендөнья сугышы чоры афиша-плакатлары мәгълүматларга байлыгы һәм почеркларының төрлелеге белән аерылып тора. ТӘҺСИ Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә куфи һәм нәсх стилендә эшләнгән плакатлар бар. Аларның да аскы өлешендә тамашачыны җәлеп итү максатыннан, яки алдагы спектакльне анонслаган өстәмә мәгълүматлар урнаштырылган. Мәсәлән: «1. Май мәсьәләсе». «Казанга сәяхәт». Гомумроссия һавада йөзү флоты файдасына хәйрия спектакле (1913 ел, 14 июнь)». 1914 ел, 14 февраль датасы куелган икенче плакатта мондый юллар бар: «Бер сәгатьлек хатын» спектакле. 12 яшьлек җырчы Фатыйма Гомәрова концерты. Х. Гомәров башкаруында декламация. Биюләр. Биюләр вакытында Каргапольский полкы оркестры уйнаячак».

1913 елдан башлап, афишаларда театр эмблемалары кулланыла башлый. Алар сәхнәнең ян декорацияләре рәвешендәге рамкада бирелә, башына тәкыя кидерелгән хатын-кыз рәсеме (элек аның урынында саз (лира) гына булган) эшләнә. Нәсх стилендә спектакль исеме күрсәтелә: мәсәлән, А. Чеховның «Аю», Г. Камал куйган «Анасы кабере өстендә».

1918 елның 15 гыйнвары датасы куелган инкыйлаби дәвер өчен типик саналган афиша: «Хәрби патриотик кичә. «Денщик Гали» спектакле. Дивертисмент (шигырьләр, музыка, җырлар, биюләр, балет, хикәя, декламацияләр; кавалеристлар, эскадроннар җырлый, курайда уйный, гимнастлар чыгышы, хәрби уеннар). Биюләр» (ТӘҺСИ Язма һәм музыкаль мирас үзәгеннән).

Мондый плакатларда, инкыйлаби романтикадан тыш, ура-патриотизм элементлары һәм гади кешеләрнең газаплы тормышы, сугыштан соңгы җимереклекләр авазы да чагылыш тапкан.

XX гасырның беренче дистә елларында эшләнгән афишалар стилистика ягыннан үзләренең ачыктан-ачык декоративлыгы, гарәп язуының катлаулы формаларын куллану, үз заманы стиленә (модерн) якын милли орнаментлар куллану белән аерылып торалар, шуның өстенә алар инкыйлабка кадәр басылып

чыккан татар китаплары бизәлешенә (китап бите өстендәге орнамент, кайма, виньетка һәм зигзаг, ромб һ.б. рәвешендәге бизәкләр) дә охшашлар.

Шушындый төрлелеккә дә карамастан, ул чор афишалары реклама характерындагы полиграфик продукция булып кына саналалар, 1920-1930 еллар плакатлары кебек сәнгати кыйммәткә дәгъва кылмыйлар.

1920 елларда татар театр афишалары бизәлешендә конструктивлык һәм массакүләм агитация сәнгате эзләре күзәтелә. Бу очракта, беренче чиратта, экспериментал театр (КЭМСТ) йогынтысына игътибар итәргә кирәк. Анда М. Барашов, К. Чеботарев, В. Фоминых, С. Хромов кебек афиша турындагы гадәтләнгән кузаллауларны юкка чыгарырга омтылган рәссамнар эшли. Афишалар артык күпсүзлелектән арындырыла, анда театрның һәм спектакльнең исемнәре куела, авторы күрсәтелә, куючыларның (режиссер, рәссам, композитор, балетмейстер, төп рольләрне башкаручыларның) исем-фамилияләре языла. Тагын бер үзенчәлеге шунда: спектакльнең исемен эре итеп, фигуралы хәрефләр белән, төп фонга контраст төстә язу (гомумән, текстны фоннан нык аерып торган төсләр белән бирү).

Рәсем графикасын куллanудан ваз кичеп, типографик алымнарга күчү текстны яңача урнаштыруга юл ача: сүзләр өлешләргә бүленә, диагональ буенча яки баскычлап һәм түгәрәк рәвешендә аркылы-торкылы урнаштырыла. Конструктив плакатларны тикшерүчеләр «1917 елга кадәр театр афишаларында моның беркайчан да булганы юк иде» дигән караштa торалар [Лапина, б. 57]. Мисал итеп Ш. Камалның «Ут», К. Тинчуринның «Ил» пьесалары буенча сәхнәләштерелгән спектакльләр афишаларын китерергә була. «UT» һәм «IL» сүзләре аларда ак фонга эре итеп кызыл хәрефләр белән язылган. «Отелло» спектакле плакаты да шундый кыскалыкка ия. Аның беренче хәрефе О плакат кәгазе биеклегенә сузылган. «ODVA» («Одва») сүзенең хәрефләре кызыл флаг фонындагы визуаль орнаментны хәтерләтә. Спектакльнең исемен стильләштерелгән хәрефләр белән бирү аның рухын һәм характерын чагылдыра (мәсәлән, Т хәрефе чүкечне хәтерләтә). Тагын характерлы бер үзенчәлек булып контраст төсләрдә (кара ак, кызыл кара, ак кызыл) эре хәрефләр белән өчпочмаклап һәм квадрат рәвешендә стандарт хәрефләрдән җыелган афиша текстларында татар тукучылык бизәкләре күз алдына китерелү тора. Хәрефләрдән тупланган гадәти типтагы афишаларда бер яки ике төстәге буяулар кулланылса, гастроль спектакльләре афишаларында исә берничә төс (сары, көрән, бронза төс) файдаланыла. Куфи стилендәге хәрефләр кулланылу эксперименты аеруча кызыклы, алар конструктив ачыклауга мохтаҗ.

К. Тинчуринның «Америкаn» пьесасы буенча 1924 елның 19 мартында сәхнәләштерелгән спектакльнең афишасы чәчәк кебек куфи стилендәге бормалы хәрефләр белән бизәлгән булса, ә инде кичәнең 14 февраль датасы куелган 1929 елның көнчыгыш клубтагы афишасы нәсх почеркына охшатылган геометрик куфи белән матур һәм зәвыклы итеп эшләнгән. Театрның 20 еллыгына (1926 ел) багышланган тантаналы кичә афишасы бик зур форматта һәм аның бизәлешендә дә шулай ук куфи стиле кулланыла.

Биредә беренче тапкыр балалар труппасы репертуары («Тычканга үлем, мәчегә көлке») һәм Театр техникумы студентлары чыгышы («Беренче адым») хакында да белдерелә.

Мәгълүм булганча, 1920 елларда татар театрында куелган беренче авангард спектакльләр - татар театр техникумының Р. Ишморат, КЭМСТ һәм актер, режиссер Ә. Мәҗитев (1900-1946), оештырып кына калмыйча, аны үзе үк иҗатка рухландырган «Бомба» [Султанова, б. 549-560] коллективлары белән хезмәттәшлегенең нәтиҗәсе.

Кызганычка каршы, авангард спектакльләрнең плакатлары аз сакланган. КФУ коллекциясендә андый тамашаларның характеры һәм эчтәлеге турында кузаллау тудырырга ярдәм иткән берничә афиша бар. Мәсәлән, сәнгать техникумының театр бүлеге әзерләп чыгарган беренче төркемнең педагогы М. Мәһдиев җитәкчелегендәге күрсәтмә спектакле бию номерлары белән баетылган хор, оркестр катнашында уза. Рәссам Никандров (исеме күрсәтелмәгән) тарафыннан бизәлгән афишада тамашаның катнашучылары татар театрының булачак артистлары: Үтәшев, З. Бикбулатова, Х. Гыйльманов, Ф. Нагаева, Г. Мансуров, Г. Хәкимовлар күрсәтелгән.

Нәкъ менә сулф (сул фронт) юнәлеше рәссамнары һәм режиссерлары афишалар эшләүдә, беренче булып, киномонтаж алымнары, цирк элементлары кулланалар. Мәсәлән «58» спектакле афишасында шундый мәгълүматлар бирелгән: С. Вәлиева-Сульва иҗаты, 4 пәрдәдә, 16 күренештә, режиссеры

К Тинчурин, музыкаль бизәлеш авторы С. Сәйдәшев, рәссамы П. Сперанский (латин хәрефләре белән татар һәм рус телләрендә язылган).

Театрның художество җитәкчелегенең, актерларның фотографияләре, төрле конфигурациядә (җилпәзә рәвешендә, диагональ яки вертикаль буенча) урнаштырылып, коллаж барлыкка китерә, шунда ук алдагы репертуар (классика, оригиналь әсәрләр, тәрҗемә спектакльләр) санап үтелә, хәтта спектакльнең макеты урнаштырыла.

1920 еллар ахырында 1930 еллар башында афишаларда әйдәүче актерларның фотографияләре бирелә башлый. Мәсәлән: 1927 елның 27 гыйнварында куелган «Таһир Зөһрә» спектакле исеме афишада диагональ буенча нәсх стилендә язылган, ике як читендә Ф. Ильская белән М. Мәһдиев фотографияләре урнаштырылган (ТР Милли музее). 1932 елның 16-17 ноябре датасы куелган афишада төп рольләрне уйнаучы актерлар янәшәсендә артистка Нәфига Араპованың да катнашуы турында өстәмә мәгълүмат җиткерелә. «Отелло» спектакленең яңартылган куелышында Отелло ролендә Мохтар Мутин уйнаячагы белдерелә. Халык артистлары С. Гыйззәтуллина-Волжская белән Г. Болгарская, атказанган артист К. Тинчурин исемнәре афишаларда еш кабатлана.

Бу афишаларны бизәүче рәссам-авторлар турында фикер йөртеп булмый, чөнки алар имзаланмаган. Ул елларда бу эшне «Татполиграф» типографиясе хәреф җыючылары, хәреф кассаларындагы мөмкинлектән чыгып, тәҗрибә рәвешендә үзләре башкаралар.

XIX гасыр рус театры афишаларында киң кулланылганча, көчле индустриаль үсеш алган дәвер үзенчәлекләрен характерлаган элементлар да барлыкка килә башлый. Андый эмблемалар күп төрле. «Үлмәс ханым» спектакленең 1926 ел, 5 февраль датасы белән эшләнгән афишасында эклектик формада гына Татар дәүләт академия театры эмблемасы урнаштырылган. Гадәттәгечә ул өстә уртага, икегә аерылган шестерня фонында битләренә каурыйлар ясалган ачык китап рәвешендә бирелгән, театрның исеме рус һәм гарәп графикасында вак хәрефләр белән татар телләрендә язылган. Ә иң өстә РСФСР гербы.

С. Сәйдәшев музеенда безгә 1920 еллар ахыры 1930 еллар башында эшләнгән афишаларда тасвирый элементларга бай эмблемаларны да очратырга туры килде. Беренче планда төзелеш вышкалары, биек-биек йортлар белән гәүдәләндерелгән индустриаль пейзаж, аның фонына заманча символлар: уңда трактор, сулда китаплар урнаштырылган. Композициянең үзәгендә шестерня һәм урак белән чүкеч фонында театр маскасы. Шунда ук ТДТ (Татар дәүләт театры) аббревиатурасы бирелгән. К. Чеботарев линогравюралары рухында иҗат ителгән Татар дәүләт эшчеләр театры эмблемасы игътибарга лаек: аның җилфердәп торган байрак фонында пролетариат фигурасы калкып тора. Режиссер Ә. Мәҗитев тарафыннан 1935 елда куелган «Саклан, шартламасын!» спектакленең премьера афишасында рәссам А. Силантьев фамилиясе беренче тапкыр искә алына (аңа кадәр ул исем театрга багышланган хезмәтләрдә очрамый).

1920 еллар ахыры 1930 еллар башындагы театр афишалары яңа пролетар тамашачы барлыкка килү турында гына түгел, ә сәнгатьнең яңа төре саналган театрга халыкны күпләп җәлеп итү максаты белән, дәүләт һәм театр җитәкчелеге күргән чаралар хакында да хәбәр итә. Гади тамашачыны театрга тарту дигәндә, аның үз-үзен тотышында этик һәм эстетик гадәтләр формалаштыру да күздә тотыла. Мәсәлән, афишада спектакль исеменнән тыш, тагын шундый киңәшләр дә тәкъдим ителә: «Өченче звоноктан соң тамаша залына керү тыела. Тышкы өс киемен салу мәҗбүри. Билет бәясе 50 тиеннән алып, 1,5 сумга кадәр. Ташламалы билетлар сатыла».

Абонемент системасы кулланыла башлый. Мәсәлән, «Кандыр буе» спектакле афишасында мондый юллар бар: «предприятиеләр заявкалары буенча 30-40% ташлама ясала, 3, 5, 8 сумлык абонементлар сатыла». «Үз өлкә бүлекләре гаризасы буенча килешү төзегән профсоюзларга һәм фабзавместкомнарга билетлар кредитка бирелә» (1932 елның 6-9 декабре датасы белән Ф. Борнаш пьесасы буенча «Тукучы Әсма» спектакле премьерасы өчен эшләнгән афишадан. Ул КФУ коллекциясендә саклана).

Театрларга махсус рәвештә эшчеләр культпоходы оештырыла. Мәсәлән, Г. Минский пьесасы буенча С. Вәлиев-Сульва сәхнәләштергән «ОДВА» спектакле (рәссамы П. Сперанский) 1931 елның 11 мартында Пролетар районы эшчеләренә генә уйнала. Ә 1933 елда К. Нәҗми пьесасы буенча режиссер

К. Тинчурин куйган «Булат бабай семьясы» спектакле (рәссамы П. Сперанский, балетмейстеры Г. Таһиров) «Социалистик кырлар һәм терлекчелек» ударникларының һәм колхозчыларның II съездында күрсәтелә. Казанның хезмәт ударникларына һәм яхшы җитештерүчеләренә театр билетлары барлык сезонга да 40 процентлы ташлама белән сатыла, алар өчен даими урыннар калдырыла. 16 яше тулмаган балалар театрга кертелми. (К. Тинчурин пьесасы буенча куелган «Беренче чәчәкләр» спектакле премьерасының 1935 ел, 14-16 февраль датасы белән эшләнгән афишасы латин хәрефләре белән язылган. Рәссамы М. Абдуллин).

Татар афишалары һәм плакатлар театрларның репертуарларын ачыкларга, әсәрне сәхнәләштерүчеләрнең (режиссерлар, рәссамнар, композиторлар һ.б.ларның) элеккеге белешмәләрдә искә алынмаган һәм мәгълүм басма китапларга кертелмәгән исемнәрен торгызырга да ярдәм итә.

Күчмә колхоз-совхоз театры спектакльләре афишалары беренче елларыннан ук профессиональ рәссамнар тарафыннан бизәлә. Әйтик, 1935 елның 5 декабрендә режиссер С. Өметбаев куйган «Шартлау» постановкасы афишасында Грибков фамилиясе (инициалы юк) бар. «Вөҗдан» спектакленең (режиссеры С. Вәлиев-Сульва, композиторы С. Сәйдәшев) рәссамы - Ю. Антонычев. Тагын шундый формалар да булган: афишаларда төп репертуарны санап чыгу белән бергә, алдагы концертта Ә. Камал җитәкчелегендә атаклы комик Х. Шөнкәр белән гармунчы Г. Мәүлеханов катнашачагы турында гына түгел, ә театр алдында торган төп бурычлар: әйтик, пролетар сәнгать социализм төзүдә, ленинчыл коммунистлар партиясе директиваларын тормышка ашыруда һ.б.ларда иң көчле корал булып саналуы да әйтелә (КФУ коллекциясеннән).

Н. Островскийның, татарчалаштырып, 1938 елда сәхнәдә куелган «Корыч ничек чыныкты?» спектакле (режиссеры Б. Фердинандов, музыкаль бизәлеш авторы Б. Виноградов, хормейстеры В. Красовский) афишасында А. Лугарев исеме тәүге тапкыр бирелә.

1930 еллар уртасында татар театры даирәсенә беренче профессиональ рәссам М. Абдуллин килгәч, афишаларда куелышта катнашкан техник персоналның да төп составын (монтаж өлеше мөдирен, сәхнә машинистын, костюмнар цехы мөдирен, парикмахерны) күрсәтә башлыйлар. Элек күзәтелмәгән бу күренеш - профессионализм дәрәҗәсе күтәрелүен, кадрларның шәхси җаваплылыклары артуны дәлилләүче факт. Безгә татар театрының беренче профессиональ рәссамнарының берсе саналган П. Сперанский тарафыннан бизәлгән афишаларны ачыкларга насыйп булды: алар «Рабиндар» (Х. Вафа, 1930 ел), «Камиль» (Һ. Такташ, 1931 ел), «Кара күләгәләр» (А.-Т. Рахманкулов, 1931 ел), «ОДВА» (Г. Минский, 1931 ел), «Таулар» (Ш. Камал, 1931 ел), «Сөрем» (Х. Җәми, 1931 ел), «Өермә» (А. Зөлкәрнәев, 1931 ел), «Тургай» (К. Тинчурин, Р. Ишморат, 1932ел), «Мәкер һәм мәхәббәт» («Коварство и любовь». Ф. Шиллер, 1932 ел). Спектакль афишалары бизәлешендә төгәлсезлекләр дә бар. Мәсәлән, Ф. Борнашның 1934 елда сәхнәләштерелгән «Яшь йөрәкләр», К. Тинчуринның 1935 елда куелган спектакльләренә афишаларны П. Сперанский түгел, ә М. Абдуллин бизәгән булган.

Татар театры тормышы турында, аның афишалары һәм плакатлары гына түгел, ә шул чор матбугаты битләрендәге язмалар да сөйли. Мәсәлән, «Йолдыз» газетасы үз укучыларына 1915 елның 18 декабрендә Г. Кариев җитәкчелегендә «Сәйяр» труппасының «Гаепсездән гаеплеләр» («Без вины виноватые») спектакле куелачагын, аның өчен махсус декорация эшләнүен хәбәр итә. 1923 елның 15 апрелендә куелачак «Зәңгәр палас» («Голубой палас») спектаклендә Үзбәк ролен К. Тинчурин уйнаячагы, махсус декорация эшләнүе хакында белешмә бирелә. Г. Девишевның «Адашкан кыз» постановкасы куелган көнне 1927 елның 13 ноябрендә татар сәхнәсендә әйләнмә түгәрәк эшли башлый, диелгән (ТР Милли музее). 1927 елда «Хөсәен Мирза» (режиссеры Г. Девишев, рәссамы П. Беньков) спектакле барганда, беренче мәртәбә прожекторлардан файдаланыла (С. Сәйдәшев музее).

Анализлар күрсәткәнчә, КЭМСТ эшен туктатуга һәм авангард рәссамнарның күбесе таралып бетүгә карамастан, афишалар бизәлешендәге стильдә давыллы дәвер чаткылары 1930 еллар уртасына кадәр сакланып кала: әйтик, спектакльләрнең исемнәре чиктән тыш эре хәрефләр белән яки диагональ буенча бирелә, я булмаса, афиша читләре буйлап урнаштырыла. Ә инде 1930 еллар ахырында афишаларның конструктивистик концепциясен татар китаплары бизәүдәге бертөрлелек һәм шаблон

системасына йөз тоткан «неоклассицистик тенденцияләр» алыштыра [Улемнова, б. 26].

1940-1950 елларда, рус театрларындагы кебек үк, гадәти шрифтлы афишалар өстенлек итә, аларда спектакльнең атамасы һәм аны сәхнәгә куючылар турында кыскача мәгълүматны чагылдырган «вполне благопристойный и добропорядочный, иначе говоря, традиционно скучный вид» [Благов, б. 98] хөкем сөрә. 1930 еллар ахырына идея-сәяси вазгыять алышына: афишаларда театрның художество җитәкчесе белән администратор исемнәре янына яңа вазифа - сәяси җитәкче (политрук) фамилиясе дә өстәлә (мәсәлән, республика районнары буйлап оештырылган гастрольләр афишаларының берсендә сәяси җитәкче С. Садыйков фамилиясе язылган). Стилистик яктан төрлелекне калыпка салынган (шаблон) форма алыштыра. Алай да афишалар бизәлешендә, сирәк кенә булса да, 1920 еллар традициясе кабатлана (Ф. Хөсни «Еллар һәм юллар». Режиссеры Ш. Сарымсаков, рәссамы Ә. Тумашев, 1956 ел). Актерларның юбилейлары белән бәйле спектакль афишалары кайвакыт аларның фотографияләре белән бизәкләп бастырыла.

1960 еллар ахырыннан башлап, татарча белмәүче тамашачылар өчен яңа текст: «зрительный зал радофицирован, обеспечивается перевод на русский язык (вторник, среда, пятница, суббота)» дигән сүзләр өстәлә.

1960-1970 елларда театр плакатларын төсле итеп чыгара башлыйлар, рәссам-плакатчылар Э. Гельмс, Л. Насыйров һ.б. пьесаның (спектакльнең) идеясен тасвирый сәнгать чаралары ярдәмендә чагылдырырга омтылалар. Казанда тасвирлы афишалар чәчәк аткан чор нәкъ менә шушы елларга туры килә. 1974 елда хәтта театр афишаларының махсус күргәзмәсе оештырыла. Н. Фәттахның «Кол Гали» (1973), Г. Боровикның «Канлы күләгәләр» (бу спектакльне күрсәтү тыела) спектакльләре өчен эшләнгән оригиналь плакатларның күргәзмәлелеге аеруча уңышлы була. Аларда сюжет түгел, ә эмоциональ-образлылык, постановканың гомум монументаль стиле сурәтләнә. Ул елларда афиша бизәлеше өстендә эшләгән рәссам-плакатчылар (М. Сутюшев, Э. Гельмс, Л. Насыйров, Р. Доминов) тәҗрибәсе әлегә киң таралыш алмаган.

Традицион шаблонга борылыш, театр формасы буларак сюжет һәм гротеск, шулай ук образларның плакатлардагы (афишалардагы) тәэсирлелеге белән кызыксына башлау - шул заманның плакат сәнгатенә хас күренеш һәм ул татар театрын да читләтеп узмаган. Театр рәссамнары (М. Сутюшев, Э. Гельмс, Р. Доминов) белән беррәттән танылган графиклар, иллюстрация осталары һәм «Чаян» журналы белән актив хезмәттәшлек итүче карикатурачылар Э. Гельмс, И. Әхмәдиев, Л. Насыйров, И. Хантимеровлар да плакатлар эшләү белән мавыгалар. Театр өчен иҗат ителгән плакатлар аларның графикаларын һәм карикатураларын хәтерләтә. Бу бигрәк тә В. Качалов исемендәге Рус драма театры спектакльләренә афишалар эшләгән, Яшь тамашачылар театрына декорация һәм костюмнар иҗат иткән Л. Насыйров үрнәгендә ачык күренә. 1966 елда рәссам Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында сәхнәләштерелгән «Хуҗа Насретдин» (режиссеры Х. Уразиков) спектакленә афиша эшли. Анда ул алгы планда ишәгенә атланып утырган, хәйләле елмаюдан күзләре кысылган Хуҗаны сурәтли. Л. Насыйров аның сын-башын каллиграфик язманы хәтерләткән җиңелчә һәм ачык сызыклар ярдәмендә гәүдәләндергән. Рәсемдә татар халык декоратив сәнгатенең милли традицияләре чагылыш тапкан: җыйнак ачык төсләрдән төрле төстәге тире кисәкләреннән төзелгән мозаиканы хәтерләтә. Күлмәге «төрекчә кыяр» белән бизәкләнгән.

Сатирик графика осталары Э. Гельмс белән И. Әхмәдиев, спектакльнең асылын ачып бирү һәм аны тагын да тулыландыру максатыннан, театр афишаларын сатирик плакат рухында бизиләр. Э. Гельмсның Ф. Яруллин пьесасы буенча сәхнәләштерелгән «Әнә килә автомобиль» спектакленә (режиссер М. Сәлимҗанов, 1974) эшләгән плакаты аның көнкүреш темаларына багышланган карикатуралары белән тәңгәлләшә. Андагы һәр деталь, кеше арасында дәрәҗәле булырга омтылып, бөтен көчен автомобиль алуга биргән затларга карата сатирик көлке хисләре уята. Клоуннарга охшатып ясалган персонажлар, уенчык фанера автомобиле карнавалны хәтерләтә. Ч. Айтматов повесте буенча куелган «Гүзәлем Әсәл» (режиссеры Т. Ходжаев, 1966) спектакленә эшләнгән афиша бөтенләй башка характерда: рәссам арткы планда үзе яраткан караңгы соры төсләр ярдәмендә текә тауга күтәрелүче юлларны сурәтли. Бу - кеше язмышындагы катлаулы кискен борылышларның метафорик образы. 1967 елда бу әсәрне сәхнәгә куючылар ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булдылар.

И. Әхмәдиев иҗаты сәхнәгә милли классиканы кайтару белән бәйле. Татар халык сәнгате традицияләрен үзенчә интерпретацияләп, ул театр афишалары бизәлешенә ачык төсләр, кабатланмас сәнгати юнәлеш өстәде (аның татар театры белән хезмәттәшлеге яңа бинага күчү чорына туры килә). К. Тинчуринның «Казан сөлгесе», Н. Исәнбәтнең «Портфельле кияү» (режиссеры М. Сәлимҗанов, 1986) спектакльләренә И. Әхмәдиев иҗат иткән плакатлар саф һәм җиңелчә юмор белән сугарылган. «Казан сөлгесе» афишасында милли киемнәрдәге егет белән кыз татар бизәкләре рәвешендә автор фамилиясе (Тинчурин) төшерелгән сөлге-флаг җилфердәтеп баралар. Алгы планда дисбе тартып мулла утыра. Аның өстендә буй-буй халат, башында зур чалма. Үзе яшьләргә курку катыш карап тора. Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» пьесасы буенча сәхнәләштерелгән атаклы спектакльнең плакатында реаль тормыш белән фантастик дөнья очраша. Композициянең уң ягында кояшлы табигать кочагында, каен төбендә, ачык сары көнбагышлар арасындагы эскәмиядә чал чәчле карт утыра. Унда шул ук фигураның ачык төстәге силуэты. Баш өстендә салават күпере, күктә йолдызлар җемелди. (Бу спектакльне сәхнәләштергән режиссер М. Сәлимҗанов, әсәр авторы Т. Миңнуллин, баш рольне башкаручы Ш. Биктимерев 1979 елда РСФСРның К. Станиславский исемендәге Дәүләт премиясе белән бүләкләнделәр.)

1980-1990 елларда стиле буенча төрле бизәлештәге спектакль күренешләренең, актерларның фотографияләре файдаланылган афишалар барлыкка килә. Аларның күп өлешен спектакльләрдән иллюстрацияләр тәшкил итә. 1920-1930 еллар традициясе торгызылып, афишаларда спектакльнең атамасы гына түгел, ә анда катнашучыларның һәм сәхнә бизәлешен тормышка ашыручыларның исем-фамилияләре дә күрсәтелә башлый.

Театр янында урамга эленгән афишаларда, автор белән режиссердан тыш, сценограф һәм композиторның да фамилияләре языла. Театрның баш рәссамы С. Скоморохов - тамашачының фантазиясен уята, катлаулы ассоциатив бәйләнешләр тудыра ала торган күп кенә афиша-плакатларның авторы. Аның Ч. Айтматовның «Ахырзаман» («Плаха»), А. Чеховның «Акчарлак» («Чайка») һ.б. спектакльләргә эшләгән афишалары тирән мәгънәле плакат характерында, алар театрга бәйсез сәнгать әсәре буларак та бәяләнергә хаклы.

Р. Исәнбәт, А. Габдуллин - дизайн өлкәсендә зур тәҗрибә туплаган, сәхнә сәнгате үзенчәлекләрен үзәккә куеп фикер йөртергә сәләтле, компьютер технологияләрен киң кулланып эшләүче белгечләр. А. Габдуллин актерларның фотографияләрен һәм шрифтларның эстетик мөмкинлекләрен тасвирый тукыма сыйфатында еш кына файдалана; аларны сценография үзенчәлекләре, тасвирый чишелеш белән оста үрә, шул ук вакытта афиша белән спектакльнең стиль бердәмлеген дә саклап кала (К. Тинчуринның «Зәңгәр шәл», Т. Миңнуллинның «Җанкисәккәем», Т. Гыйззәтнең «Кыю кызлар» спектакльләре).

Р. Исәнбәт - югары графика һәм рәсем сәнгате культурасына ия белгеч. Ул, станок формаларына тартылу белән беррәттән, символ, тамга мөмкинлекләрен дә сынап карый, фотографика һәм милли орнаментның сәнгати үзенчәлекләрен үзләштерә (И. Фоссе «Однажды летним днем»; Ж.-Б. Мольер «Дон Жуан»; Н. Исәнбәт «Хуҗа Насретдин», режиссеры Ф. Бикчәнтәев). Рәссам, әсәр темасыннан еш кына читкә китеп, төрле мәгънәви ассоциацияләр тудыручы төрле контекстларны эченә алган дөньякүләм мәдәният катламына мөрәҗәгать итә.

Хәзер театрның яңартылган репертуары белән бәйле яңа логотибы барлыкка килде, иске афишалар бизәлешенә, конструктивизм традицияләренә нигезләнгән яңа афишалар эшләнә башлады (концепция авторы Н. Агапова). Бүген театрның заман таләпләренә җавап бирә торган, тәэсирле һәм кыскартылган бердәм реклама стиле бар. Театр эшлеклеләре спектакль афишаларына куелган сәнгати таләпләрне дөрес аңлап эш итәләр. Залларда күрсәтелә торган тамашаларны рекламалауның замана технологияләре арта баруга карамастан, татар театрында афиша-плакат үзенең актуальлеген югалтмый, чөнки әле татар тамашачысы халкыбызның бай басма һәм кулдан язылган китап традициясе турында хәбәрдар.

Спектакльләрдән аермалы буларак, театр афишалары үзләренең автономия – яшәешен дәвам итә; вакыт һәм сәхнә киңлегендә театр белән тамашачы диалогын тулысынча саклаган хәлдә, алыштыргысыз документ булу әһәмиятен югалтмый: аларда театр репертуары, авторлар, күренекле актерлар турында мәгълүмат кына түгел, ә тамашачының зәвыгы,

заманча эстетик таләпләре, ягъни театр сәясәте чагылыш таба. Шуңа күрә барлык татар театрлары афишаларының коллекциясен (алар 11) бер музейда туплау турында уйлыйсы бар. Театр сәнгатенең документаль шаһитләрен тәшкил иткән бу хәзинәгә юлны белгечләр генә түгел, гади тамашачы да табар иде.

**Әдәбият**

*Аитов, Л.* Безнең остазыбыз. Г. Камал турында истәлекләр. Казан: Тат. китап нәшр., 1979. Б. 105–106.

*Благов Ю., Ключевская Е.* Мир театральной афиши // Казань. 2002. № 3–4. С. 89–99.

*Гиззат Б.* Первая театральная афиша // Советская Татария. 1956. 30 дек.

*Каримуллин А.* Татарская книга начала XX века. Казань: Тат. кн. изд-во, 1974. 320 с.

*Корнилов П.* Казанский плакат. Казань, 1929. 29 с.

*Кумысников Х.* Истоки сценического реализма. Казань: Тат. кн. изд-во, 1982. 136 с.

*Лапина К.* Конструктивизм на марше: театральный плакат 1920–1930-х годов // Сцена. 2013. № 5 (85). С. 57–61.

*Султанова Р.* КЭМСТ и татарский театр // Искусствознание. 2010. №1–2/10. С. 549–560.

*Султанова Р.* Современная сценография Татарстана. Казань, 2003. 48 с.

Татарстан: Иллюстрированная энциклопедия под общ. ред. А. М. Мазгарова, Г. С. Сабирзянова. Казань: ГУ «Институт Татарской энциклопедии АН РТ», 2013. 828 с.

*Улемнова О. Л.* Сметая веками насевшую пыль... Графический коллектив «Всадник» (1920–1924). Каталог выставки. Казань, 2014. 264с.

*Улемнова О. Л.* Искусство графики Татарстана 1920–30-х годов: автореф. дис. ... канд. искусствоведения. М., 2005. 29 с.

*Червонная С. М.* Искусство Советской Татарии. М.: Изобразительное искусство, 1978. 296 с.

*Хабутдинов А.* Между модернизмом и атеизмом, от арабского шрифта – к латинице: тюркские народы СССР в 1920-е годы // Плакат Советского Востока. Альбом-каталог. М.: Издательский дом Марджани, 2013. С. 1–5.

---

# ИСТОРИЯ ТАТАРСКОГО ТЕАТРА В ПЛАКАТНОМ ИСКУССТВЕ (1906–2016)

**Рауза Рифкатовна Султанова,**
Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ,
Россия, 420111, г. Казань, ул. Карла Маркса, 12,
rauzasultan.art@mail.ru.

В статье систематизирован материал по истории плакатного искусства в Республике Татарстан. В фокусе внимания автора оказалась история татарского театра, увиденная сквозь призму театральных афиш и плаката. В работе проанализировано 320 источников из различных фондов: ТГАТ имени Г. Камала, Научной библиотеки им. Н. И. Лобачевского Казанского (Приволжского) федерального университета, ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова Академии наук РТ, Национального музея РТ, музея им. С. Сайдашева. Предметом исследования стали содержание, стилистика, художественные особенности оформления афиш на разных этапах развития татарского театра. Новизна данной работы состоит в том, что это первое исследование по истории татарского театрального плакатного искусства, имеющего богатейшие традиции в книжной культуре татарского народа. В статье доказывается, что афиши и плакаты стали своеобразным знаком театра, отражающим сложный исторический путь, его основные тенденции развития.

**Ключевые слова**: татарский театр, татарская драматургия, афиша, плакат, искусствоведение.